СОВЕТ СОКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.38, с.Соколка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКОЛКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 38 нче йорт, Соколка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422181

тел.(факс): (85563) 3-82-05; e-mail: Sokol.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР
От 18 нче сентябрь 2019 ел.

РЕШЕНИЕ
№ 1-43

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 пункты, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Башкарма комитеты К А Р А Р  Б И Р Д Е:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме :

- Грахань авылында Совет урамында Бөек Ватан Сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү һәм кую (табличкалар, төзелеш материаллары сатып алу, территорияне төзекләндерү, килешү буенча эш өчен түләү);
- Соколка авылында Билгесез солдат һәйкәленә ремонт ясалды (койма урнаштыру, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү);
- Соколка авылында юлларга вак таш җәю (сатып алу, таш ташу, килешү буенча эш өчен түләү);
- Соколка, Соколка урманчылыгы, Грахань, Яңа Закамский, Иске Закамский бистәләрендә юлларны кардан чистарту.

« ӘЙЕ »　　　　« ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге башлыгы А.Г. Рахимзяновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Рахимзянов А.Г.